КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 29 декабрь г.Казань № 1123

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәт өчен түләүләре Бердәм тариф челтәре нигезендә хисаплап чыгарыла торган Татарстан Республикасы бюджетыннан финансланучы оешмалар хезмәткәрләренә эш хакын арттыру турында» 2011 ел, 14 июнь, 477 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәт өчен түләүләре Бердәм тариф челтәре нигезендә хисаплап чыгарыла торган Татарстан Республикасы бюджетыннан финансланучы оешмалар хезмәткәрләренә эш хакын арттыру турында» 2011 ел, 14 июнь, 477 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 24 август, 678 нче; 2011 ел, 19 октябрь, 870 нче; 2012 ел, 25 апрель, 323 нче; 2012 ел, 1 август, 653 нче; 2012 ел, 6 ноябрь, 966 нчы; 2012 ел, 10 декабрь, 1072 нче; 2013 ел, 31 июль, 538 нче; 2013 ел, 17 октябрь, 767 нче; 2013 ел, 31 декабрь, 1104 нче; 2014 ел, 16 октябрь, 762 нче; 2015 ел, 30 октябрь, 812 нче; 2016 ел, 27 июнь, 438 нче; 2016 ел, 22 сентябрь, 676 нчы; 2017 ел, 2 август, 538 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктның беренче абзацында «2015 елның 1 октябреннән» дигән сүзләрне «2018 елның 1 гыйнварыннан» дигән сүзләргә алыштырырга;

әлеге карарга теркәлгән 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2011 ел, 14 июнь, 477 нче
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 29 декабрь, 1123 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары)

| Бердәм тариф челтәренең түләү разрядлары | Тариф коэффициент-лары | Тариф ставкалары (окладлары), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 2329,0 |
| 2 | 1,047 | 2438,0 |
| 3 | 1,09 | 2539,0 |
| 4 | 1,142 | 2660,0 |
| 5 | 1,268 | 2953,0 |
| 6 | 1,407 | 3277,0 |
| 7 | 1,546 | 3601,0 |
| 8 | 1,699 | 3957,0 |
| 9 | 1,866 | 4346,0 |
| 10 | 2,048 | 4770,0 |
| 11 | 2,241 | 5219,0 |
| 12 | 2,423 | 5643,0 |
| 13 | 2,617 | 6095,0 |
| 14 | 2,813 | 6551,0 |
| 15 | 3,035 | 7069,0 |
| 16 | 3,260 | 7593,0 |
| 17 | 3,511 | 8177,0 |
| 18 | 4,499 | 10478,0 |

Искәрмә: җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (окладь) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1 – 2 разрядка түбәнрәк итеп билгеләнә.